**1. Түбәндә күрсәтелгән җавапларның кайсысы XVII гасырда патриарх Никонның реформа нәтиҗәсен чагылдыра?**

1) Патриархлык кертү
2) Изге Синодны төзү
3) Чиркәүнең җирбиләүчелек хокукларын бетерү
4) Чиркәү китапларын грек үрнәкләренә туры китереп үзгәртү

2. Түбәндә санап кителгән сәбәпләрнең кайсысы XIV гасырда Мәскәүнең күтәрелешенә этәргеч ясаган?

1) Мәскәү кенәзләре сәясәте
2) Алтын Урданың таркалуы
3) Идарә итүнең республика формасы
4) Мәскәүгә берләшү үзәге буларак альтернатива булмау

3. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы X гасырда булган вакыйганы тасвирлый?

1) Олег җиткчелегендә Новгород белән Киевны берләштерү
2) Новгород хакимиятенә варягларны чакыру
3) Урок һәм погостлар кертү
4) Любечьта кенәзләр съезды

4. Кенәзләрнең хакимлек итү еллары белән бәйле рәвештә кенәзләр һәм вакыйгалар арасындагы мөнәсәбәтне билгеләгез: беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элементны сайлап алыгыз.

| **КЕНӘЗЛӘР** | **ВАКЫЙГАЛАР** |
| --- | --- |
| **А)** Олег | **1)** древляннар восстаниесе |
| **Б)** Игорь | **2)** Хәзәр каганатының җимерелүе |
| **В)** Святослав | **3)** Уроклар һәм погостлар кертү |

**4)** Бер кенәз хакимлегендә Киев белән Новгородны берләштерү

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны туры килгән хәрефләр астына языгыз.

5. Рәсемне карагыз һәм биремне үтәгез.



Әлеге Рәсемнең нигезендә нинди тарихи вакыйга ята?

**1)** Кенәз Святослав Игоревичның Хәзәргә походы

**2)** Калка елгасы янындагы сугыш

**3)** Батый хан гаскәренең Владимирны алуы

**4)** Боз өсте сугышы

6. Кенәзләрнең Любечьтагы җыены ничәнче елда булган?

**1)** 862 елда

**2)** 988 елда

**3)** 1097 елда

**4)** 1223 елда

7. XIV гасырның беренче чирегендә Мәскәү кенәзләре Төньяк-Көнчыгыш Русьта лидерлык позициясен яулау өчен кайсы шәһәр белән көрәш алып барганнар?

**1)** Звенигород белән

**2)** Новгород белән

**3)** Тверь белән

**4)** Смоленский белән

8. Түбәндә санап кителгән шәхесләрнең кайсысы Андрей Рублев белән берлектә Мәскәү Кремле Благовещенский соборының иконостасын ясаган?

**1)** Феофан Грек

**2)** Дионисий

**3)** Симон Ушаков

**4)** Аристотель Фиораванти

9. Рәсемне карагыз.



Рәсемдә тәкъдим ителгән...

**1)** фреска

2) мозаика

3) миниатюра

4) икона

10. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы опричнина сәясәтенең бер нәтиҗәсе булган?

1) Беренче Земский соборны чакырып алу

2) Россиянең икътисадый яктан зәгыйфьләнүе

3) Россиягә Казан һәм Әстерханның кушылуы

4) Россиядә патриархлык урнашу

11. Схеманы карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




Схемада Хәзәр каганатының башкаласы нинди сан белән тамгаланган?

1) 1
2) 2
3) 3
4) 4

12. Романовлар династиясе Россия тәхетенә ничәнче гасырда килгән?

1) XIV г.
2) XV г.
3) XVI г.
4) XVII г.

13. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы XVII гасыр башындагы Фетнәнең нәтиҗәсе булган?

1) рус җирләрен Мәскәү тирәсенә берләштерү процессының тәмамлануы
2) Россиянең Новгородны һәм Псковны югалтуы
3) Билгеләнгән елларны бетерү
4) Россия тәхенә Романовлар династиясе килү

14. XVII гасырда Россия булган сугышлар һәм аларның нәтиҗәләре арасында мөнәсәбәтне билгеләгез: беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элементны сайлап алыгыз.

**СУГЫШЛАР**

А) Смоленск сугышы
Б) 1654—1667 елларда рус-поляк сугышы
В) 1676—1681 елларда рус-төрек сугышы

**НӘТИҖӘЛӘР**

1) Запорожьеның Россия составына керүе
2) Кырымның Россия империясенә кушылуы
3) Сул як ярдагы Украинаның һәм Киевның Россия составына керүе

4) Польша короле Владислав IV нең Россия тәхетенә дәгъвадан баш тартуы

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны туры килгән хәрефләр астына языгыз.

15. Монголларның Руська һөҗүм итүе кайсы гасырга карый?

1) X гасырга
2) XI гасырга
3) XIII гасырга
4) XVI гасырга

16. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Беренче рус-византия килешүе төзелү
2) Кенәзләрнең Любечь съезды
3) Хәзәр каганатының җимерелүе
4) Печенегларның тулысынча тар-мар ителүе

17. Схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.




Схемада чикләре күрсәтелгән территория белән идарә иткән Мәскәү кенәзен атагыз.

1) Даниил Александрович

2) Дмитрий Донской

3) Иван III

4) Василий III

18. Александр Невский кайсы гасырда кенәзлек иткән?

1) IX гасырда

2) XI гасырда

3) XIII гасырда

4) XV гасырда

19. Русь ничәнче елда чукындырылган?

1) 882 елда

2) 988 елда

3) 1097 елда

4) 1147 елда

20. Санап үтелгән вакыйгаларның кайсы вакыйга XI гасырга карый?

1) Русьны чукындыру

2) Любечьта кенәзләр съезды

3) Калка елгасы янындагыгы сугыш

4) Древляниннар восстаниесе

21. Туктамыш ханның Мәскәүне җимерүе кайсы кенәзнең идарә итү чорына туры килә?

1) Иван Калита

2) Дмитрий Донской

3) Василий II

4) Иван III

22. Новгород республикасында иң югары дәрәҗәдәге кеше булган?

1) митрополит

2) тиун

3) кенәз

4) посадник

24. Түбәндә санап кителгән сугышларның  кайсысында русларның дошманы монгол гаскәре булган?

1) Нева сугышы

2) Боз өсте сугышы

3) Калка елгасы буендагы сугыш

4) Грюнвальд сугышы

25. Түбәндәге документларның барлыкка килү вакыты буенча хронологик тәртиптә языгыз. Җавапны  сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Урок еллары турында указлар

2) Ярослав Правдасы

3) Стоглав

4) Владимир Мономах уставы

26. Санап кителгән вакыйгаларның кайсылары Иван IV нең идарә итү вакытына туры килә? Түбәндә китерелгән җаваплардан ике вакыйганы сайлап алыгыз һәм аларга туры килә торган цифрларны языгыз.

1) Урта һәм Түбән Идел буеның Россиягә кушылуы

2) Собор уставын кабул итү

3) Мәскәү дәүләтенә Псковны кушу

4) тыелган елларны кертү

5) Грюнвальд сугышы

27. Иван Калита үткәргән  сәясәт нәтиҗәсендә...

1) митрополит резиденциясе Мәскәүгә күчерелгән
2) Псков Мәскәү кенәзлеге составына кергән
3) Алтын Урда белән мөнәсәбәтләр кискенләшкән
4) Литва бөек кенәзлеге Мәскәүгә бәйле булуын таныган

28. Түбәндә санап кителгән җавапларның кайсысы Иван IV нең опричнина  кертүнең нәтиҗәсе булган?

1) Русьның тулысынча Алтын Урда хакимлегеннән котылуы
2) Кырым ханлыгының җимерелүе
3) Россиянең Ливон сугышында җиңүе
4) илнең икътисади яктан фәкыйрьләнүе

29. С.Т.Разин җитәкчелегендәге восстание кайсы гасырда булган?

1) XIV гасырда
2) XV гасырда
3) XVI гасырда
4) XVII гасырда

30. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсылары Иван III идарә иткән вакытта төзелгән? Түбәндә китерелгән җаваплардан ике дөресен сайлап алыгыз һәм аларга туры килә торган цифрларны языгыз.

1) Новгород Кремленең София соборы
2) Нерлида Покров чиркәве
3) Владимирда Успен соборы
4) Мәскәү Кремленең Благовещенск соборы
5) Мәскәү Кремленең кызыл кирпич стеналары

31. Елъязма буенча ничәнче гасырда Новгород хакимиятенә варяглар чакырылган?

1) VII гасырда
2) VIII гасырда
3) IX гасырда
4) X гасырда

32. XVII гасырда рус әдәбиятының күренекле шәхесе...

1) Нестор
2) Феофан Грек
3) Симеон Полоцкий
4) Дионисий

33. Түбәндәге вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапларны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) качак крестьяннарны чикләүсез эзәрлекләүне кертү
2) Россиядә патриархлык урнашу
3) Михаил Романовны патшалыкка сайлау
4) местничествоны тулысынча бетерү

34. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Мәскәүнең берләшкән рус җирләренең үзәге булуга ярдәм иткән?

1) идарә итүнең республика формасын сайлау
2) Мәскәү кенәзләренең Алтын Урдага һәм төп дошманнарына карата алып барган сәясәте
3) Мәскәү кенәзләренең Алтын Урда хакимлегенә каршы көрәштә Көнбатыш Европа илләре белән берләшүе
4) берләштерү үзәге буларак Мәскәүгә бүтән альтернативаның булмавы

35. Түбәндә күрсәтелгән җавапларның кайсысы XVII гасырда патриарх Никонның реформа нәтиҗәсен чагылдыра?

1) Россиядә патриархлык урнашу

2) чиркәү йолаларын үзгәртү

3) чиркәүне дәүләттән аеру

4) чиркәүнең җир милкен дәүләткә тапшыру

36.“Урда хакимлеге чорында рус кенәзләренең идарә итү хокукы булуын раслый торган хан грамотасы” аңлатмасына туры килә торган терминны языгыз.

37. Россиядә Фетнәле заман кайсы чорга карый?

1) XV гасырның икенче чиреге

2) XVI гасырның өченче чиреге

3) XVI гасыр ахыры — XVII гасыр башы

4) XVII гасыр ахыры

38. Мәскәү кенәзе Василий III нең идарә итү вакыты ничәнче гасырга карый?

1) XIII гасырга

2) XIV гасырга

3) XVI гасырга

4) XVII гасырга

39. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы Борынгы рус дәүләтенең мөстәкыйль җирләргә бүленү чорына туры килә?

1) Ярослав Правдасы төзелү

2) Мәскәүнең беренче тапкыр елъязмада искә алынуы

3) Русьны чукындыру

4) Киевта Владимир Мономахның хакимлек итә башлавы

40. Схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.




Схемада уклар белән күрсәтелгән хәрби походларның кайсы монарх хакимлек итү вакытында булуын билгеләгез.

**1)** Иван III

**2)** Иван IV

**3)** Алексей Михайлович

**4)** Пётр I

41. Елъязмалар буенча ничәнче гасырда Новгородка кенәзлек итәргә варяглар чакырылган?

1) VI гасырда

2) VII гасырда

3) VIII гасырда

4) IX гасырда

42. Түбәндә санап кителгәннәрдән кайсысы Батыйның Руська һөҗүм итүенең бер нәтиҗәсе булып торган?

1) Русьның мөстәкыйль җирләргә таркала башлавы

2) рус кенәзләренә бөек кенәзлеккә ярлык алу зарурлыгы

3) бояр һәм кенәз вотчиналары барлыкка килү

4) Батый ханның Новгородны җимерүе сәбәпле Новгород җиренең таркалуы

43. Россиядә XVII гасырдагы вакыйгалар белән бәйле барлыкка килгән терминнарны күрсәтегез. Исемлектән ике терминны сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) патриархлык

2) мануфактура

3) «яңа строй» полклары

4) укчылар

5) Земский собор

44. Василий III нең хакимлек итүе ничәнче гасырга карый?

1) XIV гасырга

2) XV гасырга

3) XVI гасырга

4) XVII гасырга

45. Рәсемне  карагыз һәм биремне үтәгез.



Әлеге архитектура истәлеге ничәнче гасырда төзелгән?

1) X гасырда

2) XII гасырда

3) XIV гасырда

4) XVI гасырда

46. Түбәндә санап кителгәннәрдән кайсысы XII— XIII гасырларда Русьта уделлар системасы барлыкка  килүнең  бер  сәбәбе булган?

1) Рюриковичлар династиясенең тармаклануы

2) Руська монголлар һөҗүме

3) христианлык кабул ителү

4) хазарлар һәм печенеглар һөҗүме  куркынычы

47. Россиядә  XVII гасырда барлыкка килгән, кул техникасына һәм хезмәт бүленешенә көйләнгән предприятиеләр ничек дип аталган?

1) мануфактуралар

2) фабрикалар

3) цехлар

4) гильдияләр

48. Рус җирләренең Көнбатыш илбасарлары тарафыннан басып алуларын туктатырга мөмкинлек биргән  хәрби җиңүләрне күрсәтегез.

1) Альта елгасы янындагы сугыш һәм Калка елгасы янындагы сугыш

2) Нева елгасы янындагы сугыш һәм Боз өсте сугышы

3) Вожа елгасы янындагы сугыш һәм Куликово сугышы

4) Грюнвальд сугышы һәм Шелонь елгасы янындагы сугышы

49. Кайсы елга янындагы сугышта Александр Ярославич швед гаскәрләрен җиңгән?

1) Сить

2) Калка

3) Нева

4) Шелонь

50. Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны  сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Степан Разин җиткчелегендәге восстание

2) Михаил Романовны патша итеп сайлау

3) патша улы Дмитрийның  Угличта һәлак булуы

4) патриарх Никонның чиркәү реформасы башлануы

51. “1610 елда Василий Шуйскийны бәреп төшергәннән соң барлыкка килгән боярлардан торган хакимият” аңлатмасына туры килгән төшенчәне языгыз.
52. Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Борис Годунов хакимлек итә башлау
2) Алексей Михайлович хакимлек итә башлау
3) патриарх Никонның чиркәү реформасы
4) Михаил Фёдоровичны патшалыкка сайлау

53. Борынгы Русь дәүләтенә һәм таркаулык чорында рус җирләренә карата характерстикаларны чагыштырыгыз. Беренче баганага – охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын языгыз.

1) барлык рус җирләренең бердәм сәяси үзәге булу
2) Русьта яшәүчеләрнең бердәм борынгы рус халкыннан килеп чыгуы
3) кенәзләрнең илнең сәяси бердәмлеген сакларга тырышулары
4) кәсепчелек һәм сәүдә үсеше

54. Русьны чукындыру ничәнче елда булган?

1) 945 елда
2) 972 елда
3) 988 елда
4) 1036 елда

55. Борынгы Русьта кенәзләр кеременең чиркәү файдасына күчүе ничек дип

аталган?

1) дисәтинә

2) чыгым

3) оброк

4) вира

56. Схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.




Схемада билгеләнгән территория белән хакимлек иткән Мәскәү кенәзен атагыз.

1) Даниил Александрович

2) Дмитрий Донской

3) Иван III

4) Василий III

57. Александр Невский ничәнче гасырда хакимлек иткән?

1) IX гасырда

2) XI гасырда

3) XIII гасырда

4) XV гасырда

58. «Замана еллары  повесте» («Повесть временных лет») варягларның Новгородка ничәнче елда чакырылуы турында хәбәр итә?

1) 862 елда

2) 882 елда

3) 907 елда

4) 945 елда

59. Владимир Мономах ничәнче гасырда  бөек Киев кенәзе булган?

1) X гасырда

2) XI гасырда

3) XII гасырда

4) XIII гасырда

60. Түбәндә санап кителгәннәрдән кайсысы 1648 елда Мәскәүдә халык дулкынлануларының бер нәтиҗәсе булган?

1) местничествоны бетерү

2) крестьяннарның Юрий көненә күчү хокукын бетерү

3) бакыр акчалар бастырмый башлау

4) качак крестьяннарны чикләүсез эзәрлекләүне кертү

61. “1497 елда хокуклар нормасын системага салу максатында төзелгән  Россия дәүләтенең законнар җыелмасы” аңлатмасына туры килә торган терминны языгыз.

62. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы Алексей Михайлович хакимлек итү  чорына карый? Исемлектән ике вакыйганы сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) Яшерен эшләр приказы төзелү

2) опричнина оешу

**3)** тыелган еллар кертелү

**4)** сабаклар һәм погостлар кертелү

**5)** Бакыр фетнәсе

63. Түбәндә санап кителгәннәрдән кайсысы Иван IV үткәргән тышкы сәясәтнең бер нәтиҗәсе булган?

**1)** Себернең Россия составына тулысынча керүе

**2)** Россиянең Балтик диңгезенә чыгу мөмкинлеген алуы

**3)** Россиянең Кавказ артында яңа җирләргә ия булуы

**4)** Россиягә Казан һәм Әстерхан ханлыкларының кушылуы

64. Схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.



Схемада күрсәтелгән маршрут буенча үткәрелгән уңышлы хәрби поход кайсы кенәз эшчәнлегенә карый?

**1)** Рюрик

**2)** Олег

**3)** Мстислав Великий

**4)** Юрий Долгорукий

65. Качак крестьяннарны чикләүсез эзәрлекләү турында Собор уложениесе ничәнче гасырда кабул ителгән?

**1)** XIV гасырда

**2)** XV гасырда

**3)** XVI гасырда

**4)** XVII гасырда

66. Схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.




Схемада күрсәтелгән маршрут буенча үткәрелгән поход кайсы тарихи эшлекле җитәкчелегендә башкарылган?

1) Владимир Атласов

2) Ермак Тимофеевич

3) Ерофей Хабаров

4) Семён Дежнёв

67. Түбәндә санап кителгән вакыйганың кайсысы X гасырда булган?

1) варягларны кенәзлек итүгә чакыру

2) Хәзәр каганатын җимерү

3) башкаласы Киев булган Борынгы рус дәүләте төзелү

4) беренче язма законнар җыелмасы -  Русская Правда төзелү

68. Түбәндә санап кителгәннәрдән кайсысы Фетнәнең бер нәтиҗәсе булган?

1) Романовлар династиясе патшалык итә башлау

2) «Сайланган рада» реформалары

3) укчылар гаскәре төзелү

4) Земский соборлар чакырыла башлау

69. Россиянең дәүләт башлыклары һәм алар  идарә  итү вакытында  булган вакыйгалар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **РОССИЯНЕҢ ДӘҮЛӘТ БАШЛЫКЛАРЫ** | **ВАКЫЙГАЛАР** |
|---|---|
| **А)** Иван IV | **1)** Смоленск сугышы |
| **Б)** Михаил Фёдорович | **2)** Новгород һәм Тверьнең Мәскәү дәүләтенә кушылуы |
| **В)** Алексей Михайлович | **3)** Богдан Хмельницкий восстаниесе |

**4)** Ливон сугышы

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

70. Түбәндә санап кителгәннәрдән кайсысы Русьны чукындыруның бер нәтиҗәсе булган?

**1)** Византия империясе белән мәдәни бәйләнешләр урнашу

**2)** Борынгы Русь дәүләте барлыкка килү

**3)** Борынгы Русь дәүләтенең мөстәкыйль җирләргә таркалуы

**4)** кенәз Владимирның Киев тәхете өчен көрәштә җиңүе

71. “XV - XVII гасырларда Россия дәүләтендә аерым кешеләр арасында аларның нәсел дәрәҗәсенә карап хезмәт вазифаларын бүлү” аңлатмасына туры килгән терминны языгыз.

72. Рәсемне карагыз һәм биремне үтәгез.



Бу рәсемдә тасвирланган сәнгать төрен күрсәтегез.

**1)** фреска

**2)** скань

**3)** миниатюра

**4)** зернь

73. Батый гаскәрләре һөҗүменә озак каршылык күрсәтү сәбәпле Батый хан нинди шәһәрне “Усал шәһәр” (“Злой город”) дип атаган?

**1)** Смоленск

**2)** Владимир

**3)** Новгород

**4)** Козельск

74. Схеманы карагыз.




Схемада тасвирланган вакыйгалар ничәнче елда булган?

**1)** 1242 елда

**2)** 1380 елда

3) 1410 елда

4) 1480 елда

75. 1237—1242 елларда Батый ханның рус җирләренә һөҗүм итүе барышында кайсы шәһәрләр җимерелмичә калган? Исемлектән ике шәһәр исемен сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) Рязань

2) Владимир

3) Новгород

4) Псков

5) Киев

76. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы XIII гасырга туры килә?

1) елъязмада беренче тапкыр Мәскәүнең искә алынуы

2) Батый ханның Рязаньны  яндыруы

3) кенәз Святославның Хәзәр каганатын җимерүе

4) Владимир Мономахны Киевка кенәзлек итәргә чакырылуы

77. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы "Сайланган рада" тарафыннан башкарылган?

1) Россиядә патриархлык оешу

2) Соборный уложениене кабул ителү

3) коллегияләр төзелү

4) хәрби күтәрелешләр вакытында местничестволарны чикләү

78. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Иван IV нең тышкы сәясәт нәтиҗәсе булган?

1) Россиягә Урта һәм Түбән Идел буйларының кушылуы

2) Россиянең Балтик диңгезенә чыгу мөмкинлеген алуы

3) Россиягә Сул як Украинаның кушылуы

4) Россия составына Көнчыгыш Себернең керүе

79. Мәскәү тирәсендә рус җирләренең берләшү процессы тәмамлану кайсы гасырга карый?

1) XIV гасырга

2) XV гасырга

3) XVI гасырга

4) XVII гасырга

80. XIII гасырның беренче яртысында швед гаскәрләрен җиңү кайсы елга янында булган?

1) Калка

2) Нева

3) Дон

4) Угра

81. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы XII гасырда Борынгы Русь дәүләтенең мөстәкыйль җирләргә такала башлавының бер сәбәбе булган?

1) Русская Правда законнар җыелмасы төзелү

2) эре җирбиләүчелекнең үсүе

3) христианлык кабул ителү

4) Руська варягларның чакырылуы

82. "Рус каһарманнарының батырлыгы макталган халык авыз иҗаты әсәрләре һәм шигъри хикәятләр" аңлатмасына туры килә торган терминны языгыз.

83. "1649 елда Земский собор тарафыннан кабул ителгән Россия дәүләтенең законнар җыелмасы" аңлатмасына туры килә торган терминны языгыз.

84. Вакыйгалар һәм алар белән бәйле Мәскәү кенәзләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **ВАКЫЙГАЛАР** | **КЕНӘЗЛӘР** |
|---|---|
| **А)** Ермакның Себергә походы башлану | **1)** Иван Калита |
| **Б)** Шелонь елгасы янындагы сугыш | **2)** Дмитрий Донской |
| **В)** Туктамыш ханның Мәскәүне җимерүе | **3)** Иван III |
| | **4)** Иван IV |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

85. Фетнә вакытында Беренче һәм Икенче ополчениеләрнең эшчәнлеген чагыштырыгыз. Беренче баганага – охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын языгыз.

**1)** Польша басып алучыларына каршы тору

**2)** Дмитрий Пожарскийның катнашуы

**3)** Рязаньда хәрәкәт формалашу

**4)** Кузьма Мининның катнашуы

86. 1648 елда Мәскәүдә халык дулкынлануларының бер нәтиҗәсе булып нәрсә торган?

**1)** опричнина оешу

**2)** бакыр акчаларны бетерү

**3)** Земский собор чакырылу

**4)** крестьяннарның икенче хуҗага күчүләрен Юрий көне белән чикләү

87. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы опричнина сәясәте үткәрүнең бер нәтиҗәсе булган?

**1)** Беренче Земский соборны чакыру

2) Ливон сугышы башлану

3) патшаның шәхси власте арту

4) укчылар гаскәре төзелү

88. Италия осталары кайсы архитектура истәлекләрен төзү белән җитәкчелек иткәннәр?

1) Киевта һәм Новгородта София соборлары

2) Владимирда Успен һәм Дмитриев соборлары

3) Новгород Кремленең диварлары һәм манарасы

4) Мәскәү Кремленең Успен һәм Архангельск соборлары

89. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.



Рәсемдә тасвирланган сугыш кайда булган?

1) Калка елгасы янында

2) Сити елгасы янында

3) Чуд күле янында

4) Воже елгасы янында

90. Рәсемне карагыз һәм биремне үтәгез.



Рәсемдә күрсәтелгән сынлы сәнгать төрен күрсәтегез.

1) фреска
2) мозаика
3) миниатюра
4) икона

91. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы XVII гасырга карый?

1) тыелган еллар кертелү
2) укчылар гаскәре оешу
3) “яңа строй” полкы төзелү
4) беренче Земский соборны чакыру

92. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Иван IV тарафыннан опричнина кертүнең бер нәтиҗәсе булган?

1) Русьның Урда хакимлегеннән тулысынча азат ителүе

2) Кырым ханлыгын тар-мар итү

3) Россиянең Ливон сугышында җиңүе

4) илнең икътисадый яктан көчсезләнүе

93. С.Т. Разин җитәкчелегендәге восстание ничәнче гасырда булган?

1) XIV гасырда

2) XV гасырда

3) XVI гасырда

4) XVII гасырда

94. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Иван III хакимлек итү чорында төзелгән? Җаваплардан ике дөресен сайлап алыгыз һәм аларга туры килә торган цифрларны языгыз.

1) Новгород Кремленең София соборы

2) Нерлида Покров чиркәве

3) Владимирда Успен соборы

4) Мәскәү Кремленең Благовещенск соборы

5) Мәскәү Кремленең кызыл кирпич стеналары

95. XVII гасырда күренекле рус әдәбияты эшлеклесе кем булган?

1) Нестор

2) Феофан Грек

3) Симеон Полоцкий

4) Дионисий

97. Вакыйгалар һәм алар белән бәйле дәүләт башлыклары арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

**ВАКЫЙГАЛАР**

**А)** Кормлениеләр бетерелү

**Б)** Барлык крестьяннары бер вакытта Юрий көненә күчерүне кертү

**В)** Туктамыш ханның Мәскәүне җимерүе

**ДӘҮЛӘТ БАШЛЫКЛАРЫ**

**1)** Иван Калита

**2)** Дмитрий Донской

**3)** Иван III

**4)** Иван IV

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

98. Россиядә Фетнәле заман ничәнче гасырга карый?

**1)** XV гасырның икенче чирегенә

**2)** XVI гасырның өченче чирегенә

**3)** XVI гасыр ахыры—XVII гасыр башына

**4)** XVII гасыр ахырына

99. Мәскәү дәүләте башлыклары һәм алар хакимлек итү чорында Мәскәү дәүләтенә кушылган шәһәрләр арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

**ДӘҮЛӘТ БАШЛЫКЛАРЫ**

**А)** Иван III

**Б)** Василий III

**В)** Даниил Александрович

**ШӘҺӘРЛӘР**

**1)** Коломна һәм Переяславль-Залесский

**2)** Новгород һәм Тверь

**3)** Псков һәм Смоленск

**4)** Киев һәм Переяславль-Киевский

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

100. Мәскәү кенәзе Василий III ничәнче гасырда хакимлек иткән?

**1)** XIII гасырда

**2)** XIV гасырда

**3)** XVI гасырда

**4)** XVII гасырда

101. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы XI гасырга карый?

**1)** кенәз Олег хакимлегендә Киев һәм Новгородны берләштерү

**2)** кенәз Святославның Хәзәр каганатын җимерүе

**3)** Любечьта кенәзләр съезды

**4)** елъязмада беренче тапкыр Мәскәүнең искә алынуы

102. Ярослав Правдасы ничәнче гасырда төзелгән?

**1)** VIII гасырда

**2)** IX гасырда

**3)** X гасырда

**4)** XI гасырда

103. Схеманы карагыз.



Схемада билгеләнгән Мәскәү кенәзлеге (Россия дәүләте) чикләре кайсы патшаның хакимлек итүе тәмамлану вакытына туры килә?

1) Василий I
2) Иван III
3) Василий III
4) Михаил Романов

104. Авторы Киев-Печора монастыре монахы Нестор булган борынгы рус әдәбияте ядкарен күрсәтегез.

105. Рус җирләрен берләштерүдә үзәк рольне алу өчен көрәштә Мәскәү һәм Тверьның позицияләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага – охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын языгыз.

| | |
|---|---|
| 1) | кенәз тәхетендә Рюрикларның варислары утыруы |
| 2) | кенәзгә митрополитның ярдәм итүе |
| 3) | XIV гасырның беренче яртысында Урдага каршы көчле восстание нәтиҗәсендә кенәзлекнең көчсезләнүе |
| 4) | сәүдә өчен уңайлы урында урнашу |

106. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Русьның мөстәкыйль җирләргә таркалуының бер сәбәбе булган?

| | | |
|---|---|---|
| | 1) | Русьның оборона сәләте кимү |
| | 2) | Киев кенәзе власте көчәю |
| | 3) | борынгы рус мәдәнияте таркалу |
| | 4) | башка дәүләтләр белән сәүдә бетү |

1) “Закон һәм иркенлек турында” («Слово о законе и благодати»)
2) «Балаларга сабак» («Поучение детям»)
3) «Замана еллары  повесте» («Повесть временных лет»)
4) “Игорь полкы турында  хикәя” («Слово о полку Игореве»)

107. Схеманы карагыз.




Схемада кем җитәкчелегендә баш күтәрүчеләрнең хәрәкәтләре һәм халык восстаниесе районнары билгеләнгән?

1) Е.И. Пугачёв

2) С.Т. Разин

3) К.А. Булавин

4) И.И. Болотников

108. Русьта кенәзнең ясак җыюы ничек дип аталган?

1) дисәтинә
2) җан башыннан түләү
3) вира
4) вервь

109. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы XV гасыр ахыры—XVI гасыр башында Россия дәүләтен ныгыту һәм үзәкләштерү процессының бер нәтиҗәсе булган?

1) даими эшли торган үзәк идарә органнарының барлыкка килүе
2) Бояр думасын тарату
3) Земский собор эшчәнлеген туктату
4) качак крестьяннарны чикләүсез эзәрлекләү кертү

110. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы XIII гасыда булган?

1) Батый ханның Төньяк-Көнчыгыш Русьны тар-мар итүе
2) Туктамыш ханның Мәскәүне яндыруы
3) кенәз Игорь Святославичның кыпчакларга походы
4) Куликово сугышы

111. Батый хан яулары вакытында монголлар кайсы шәһәрне ала алмаганнар?

1) Новгородны
2) Киевны
3) Козельскийны
4) Рязаньны

112. Елъязмада әйтелгәнчә, IX гасырда варяг кенәзләрен чакыруның бер сәбәбе нәрсә булган?

1) Русьның Хәзәр каганатын тар-мар итүе
2) Русьның Византия белән уңышсыз тәмамланган сугышы

**3)** кыпчакларның Руська һөҗүмнәре

**4)** Русьның төньягында кабиләләр арасында дошманлык урнашу

113. Ничәнче гасырда Рус Православие Чиркәве таркалган?

**1)** XV гасырда

**2)** XVI гасырда

**3)** XVII гасырда

**4)** XVIII гасырда

114. Ничәнче гасырда Мәскәү кенәзләре династиясе хакимлек итә башлаган?

**1)** XI гасырда

**2)** XII гасырда

**3)** XIII гасырда

**4)** XIV гасырда

115. Любечьта кенәзләр съезды ничәнче елда була?

**1)** 945 елда

**2)** 988 елда

**3)** 1097 елда

**4)** 1113 елда

116. Батый хан гаскәрләренең рус җирләренә һөҗүме ничәнче гасырга карый?

**1)** XI гасырга

**2)** XII гасырга

**3)** XIII гасырга

**4)** XIV гасырга

117. Иван  Калита ничәнче елларда хакимлек  иткән?

**1)** 1303— 1325 елларда

**2)** 1325— 1340 елларда

**3)** 1340— 1353 елларда

**4)** 1353— 1359 елларда

118. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы XVII гасырда булган?

**1)** местничествоны тулысынча бетерү

**2)** җан башыннан түләү кертү

**3)** Ермакның Себергә сәфәре

**4)** Россиядә патриархлык оешу

119. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы иң ахырда булган?

**1)** Шелонь елгасы янындагы сугыш

**2)** Угра елгасы янындагы “тору”

**3)** Псковның  Мәскәү кенәзлегенә кушылуы

**4)** Тверьның Мәскәү кенәзлегенә кушылуы

120. Россиягә Әстерхан һәм Казан ханлыклары, Көнбатыш Себер ничәнче гасырда кушылган?

**1)** XV гасырда

**2)** XVI гасырда

**3)** XVII гасырда

**4)** XVIII гасырда

121.  Рус җирләре ничәнче елда Урда хакимлегеннән тулысынча азат булган?

**1)** 1462 елда

**2)** 1480 елда

3) 1497 елда

4) 1505 елда

122. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы IX гасырга карый?

1) үзәге Киев булган Борынгы Русь дәүләте барлыкка килү

2) Борынгы Русь дәүләтенең мөстәкыйль җирләргә таркалуы

3) Батый ханның рус җирләренә һөҗүм итүе

4) рус җирләренең Мәскәү тирәсендә берләшә башлавы

123. Ничәнче елда рус гаскәрләре Куликово кырында Мамай хан гаскәрләрен җиңгәннәр?

1) 1223 елда

2) 1240 елда

3) 1380 елда

4) 1480 елда

124. Романовлар династиясенең беренче вәкиле Россия тәхетенә ничәнче елда утырган?

1) 1598 елда

2) 1613 елда

3) 1649 елда

4) 1672 елда

125. Опричнина сәясәте ничәнче гасырда үткәрелгән?

1) XIII гасырда

2) XIV гасырда

3) XV гасырда

4) XVI гасырда

126. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы XIV гасырда булган?

**1)** Боз өсте  сугышы

**2)** Куликово сугышы

**3)** Калка елгасы янындагы сугыш

**4)** Угра елгасы янындагы “тору”

127. Русская Правда законнар җыелмасы төзелү ничәнче гасырга карый?

**1)** IX гасырга

**2)** X гасырга

**3)** XI гасырга

**4)** XII гасырга

128. Рус җирләрен берләштерү төгәлләнү һәм бердәм Россия дәүләте төзелү ничәнче гасырга карый?

**1)** XIV гасыр ахырына

**2)** XVI гасыр башына

**3)** XVII гасыр ахырына

**4)** XVIII гасыр уртасына

129. Кенәз Игорьның Византиягә походлары ничәнче елларда булган?

**1)** 907 һәм 911 елларда

**2)** 941 һәм 944 елларда

**3)** 970 һәм 972 елларда

**4)** 988 һәм 990 елларда

130. Куликово сугышы ничәнче елда булган?

**1)** 1185 елда

**2)** 1242 елда

**3)** 1380 елда

1410 елда

**4)**

131. Төньяк-Көнчыгыш Русьның Урда хакимлегенә керүе ничәнче гасырга карый?

**1)** XI гасырга

**2)** XII гасырга

**3)** XIII гасырга

**4)** XIV гасырга

132. XII— XV гасырларда Новгород республикасында сайлап куела торган шәһәр ополчениесе җитәкчесе ничек дип аталган?

**1)** посадник

**2)** воевода

**3)** мең башы

**4)** кенәз

133. Мәскәү елъязмада беренче тапкыр искә алынганда аның кенәзе кем булган?

**1)** Юрий Долгорукий

**2)** Андрей Боголюбский

**3)** Даниил Александрович

**4)** Иван Калита

134. Рус гаскәрләре Куликово сугышында кем җитәкчелегендә җиңүгә ирешәләр?

**1)** Юрий Долгорукий

**2)** Александр Невский

**3)** Дмитрий Донской

**4)** Иван III

135. XII— XV гасырларда Новгородта сайланып куела торган халык ополчениесе җитәкчесе  ничек дип аталган?

1) посадник
2) мең башы
3) тиун
4) воевода

136. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Иван IV нең тышкы сәясәтенең бер нәтиҗәсе булган?

1) Осман империясе белән солых төзелү
2) Россиянең Ливон сугышында җиңелүе
3) Польша патшалыгының Россиягә кушылуы
4) Россия белән Кытай арасында беренче язма килешү төзелү

137. Феофан Грек, Андрей Рублёв – кемнәр?

1) борынгы рус төзүчеләре (зодчие)
2) борынгы рус икона ясаучылары
3) Славян-грек-латин академиясенә нигез салучылар
4) Россиядә беренче басма китапны чыгаручылар

138. Мәскәү Кремленең соборларын төзүдә катнашкан төзүчеләрне (зодчие) күрсәтегез.

1) Алевиз Новый, Аристотель Фиораванти
2) Барма и Постник
3) Матвей Казаков, Василий Баженов
4) Доменико Трезини, Варфоломей Растрелли

139. Аристотель Фиораванти һәм Алевиз Новый – кемнәр?

1) Иван III хакимлек итү чорындагы төзүчеләр (зодчие)

2) Екатерина II хакимлек итү чорындагы композиторлар

3) Иван IV хакимлек итү чорындагы сәяси эшлекләләр

4) Петр I хакимлек итү чорындагы чит ил хәрби белгечләре

140. Схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.




Схемада уклар белән күрсәтелгән вакыйгалар ничәнче елда булган?

1) 1036 елда

2) 1185 елда

3) 1223 елда

4) 1380 елда

141. Схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.




Схемада уклар белән күрсәтелгән сугышның датасын күрсәтегез.

1) 1223 елның 31 мае

2) 1240 елның15 июле

3) 1242 елның 5 апреле

4) 1380 елның 8 сентябре

142. Схеманы  карагыз.




Схемада нинди территория күрсәтелгән?

1) Новгород җирләре

2) Владимир-Суздаль кенәзлеге

3) Польша корольлеге

4) Полоцк кенәзлеге

143. Схеманы карагыз.




Схемада флажок белән күрсәтелгән урында нинди вакыйга булган?

**1)** Нева сугышы

**2)** Боз өсте сугышы

**3)** Угра елгасы янындагы кара-каршы тору

**4)** Сить елгасы янындагы сугыш

144. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.



Борынгы рус төзелеш сәнгате истәлеге булган әлеге корылма ничәнче гасырга карый?

1) VIII гасырга

2) IX гасырга

3) X гасырга

4) XI гасырга

145. Рәсемне карагыз һәм биремне үтәгез.



Әлеге һәйкәл ничәнче гасырда төзелгән?

1) X гасырда

2) XII гасырда

3) XIV гасырда

4) XVI гасырда

146. Рәсемне карагыз һәм биремне үтәгез.



Әлеге һәйкәл Россия тарихында нинди вакыйгалар уңае белән куелган?

1) опричнина

2) Фетнәле вакыт

3) Петр I нең реформалар эпохасы

4) Сарай переворотлары эпохасы

147. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Укчылар гаскәре формалашу
2) Батый ханның Төньяк-Көнчыгыш Руська һөҗүме
3) Русская Правда төзелә башлау
4) Новгород-северский кенәзе Игорьның кыпчакларга каршы походы

148. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) кенәз Владимирның Русьны чукындыруы
2) Рюрикның Новгородта кенәзлек итә башлавы
3) Святославның Хәзәр каганатын җимерүе
4) Любечьта кенәзләр съезды

149. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Нева сугышы
2) Угра елгасы янындагы кара-каршы тору
3) Тверьда Урдага каршы восстание
4) Олег Вещийның Киевны басып алуы

150. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Руська варягларны чакыру
2) Киевта Зирәк Ярославның идарә итә башлавы

3) Русьны чукындыру

4) Игорь Святославичның кыпчакларга каршы походы

151. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Туктамыш ханның Мәскәүгә походы

2) Лесной авылы янындагы бәрелеш

3) Угра елгасы янындагы кара-каршы тору

4) Сить елгасы янындагы сугыш

152. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Тоз фетнәсе

2) Д. Пожарский һәм К. Минин гаскәрләренең Мәскәүне азат итүе

3) патша кызы Софьяны Россия дәүләте белән идарә итүдә катнашудан читләштерү

4) Кондратий Булавин җитәкчелегендәге восстание

153. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Любечьта кенәзләр съезды

2) Калка елгасы янындагы сугыш

3) Елъязмада беренче тапкыр Мәскәү турында искә алыну

4) Куликово сугышы

154. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Тоз фетнәсе

2) Д. Пожарский һәм К. Минин гаскәрләренең Мәскәүне Польша интервентларыннан азат итүе

3) Борис Годуновны патшалыкка сайлау
4) Ермак Тимофеевич җитәкчелегендә казакларның Себергә походы

155. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) «Замана еллары повесте» язылу
2) Нева сугышы
3) кенәз Олегның Византиягә походы
4) Новгородка варяг кензләрен чакыру

156. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Төньяк сугышы башлану
2) Идел буеның Россия составына керүе
3) Речь Посполитая белән “Мәңгелек солых” төзелү
4) Кырымның Россия империясенә кушылуы

157. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Боз өсте сугышы
2) Хәзәр каганатын тар-мар итү
3) Туктамыш ханның Мәскәүне җимерүе
4) Угра елгасы янындагы кара-каршы тору

158. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Нева сугышы
2) Новгород-северский кенәзе Игорьның кыпчакларга каршы походы
3) Калка елгасы янындагы сугыш

4) Угра елгасы  янындагы кара-каршы тору

159. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны  сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Иван III нең Судебникны кабул итүе
2) Нева  сугышы
3) Новгородның Мәскәү кенәзлегенә кушылуы
4) Любечьта кенәзләр съезды

160. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны  сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Иван IV нең Судебнигы
2) Алексей Михайловичның Соборный Уложениесе
3) Өч көнлек барщина турында Манифест
4) Владимир Мономах Уставы

161. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны  сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Русьны чукындыру
2) Игорь Святославичның кыпчакларга каршы походы
3) Елъязмада беренче тапкыр Мәскәү турында искә алыну
4) кенәз Олегның Киев һәм Новгородны берләштерүе

162. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны  сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Иван Калитаның Мәскәүдә кенәзлек итә башлавы
2) Калка елгасы янындагы сугыш
3) Тверның Мәскәүгә кушылуы
4) Ливон сугышының тәмамлануы

163. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Русьта христианлык кабул ителү
2) Новгородка варягларның чакырылуы
3) Зирәк Ярославның печенегларны тар-мар итүе
4) Батый ханның рус җирләренә һөҗүме

164. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Русская Правда законнар җыелмасының беренче өлеше язылу
2) Нева сугышы
3) кенәз Святославның Идел Болгариясенә походы
4) Новгородка варягларның чакырылуы

165. Алдагы вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Җавапны сайлап алынган элементларның цифрлары эзлеклелегендә күрсәтегез.

1) Кенәз Олегның Патша шәһәренә походы
2) Русская Правда языла башлау
3) урок һәм погостлар кертелү
4) елъязмада беренче тапкыр Мәскәү турында искә алыну

